# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

## КАРАР №14

III чакырылыш чираттан тыш утырышы Урыссу ш.т.п. "17" март 2020 ел

*2020 елга Ютазы муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның прогноз планын (программасын) раслау турында*

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, «Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 21.12.2001 ел, № 178-ФЗ Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 30.05.2008 ел, № 115 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында»гы Нигезләмә нигезендә, «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 78 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Кушымта нигезендә 2020 елга Ютазы муниципаль районының күчемсез муниципаль милекне хосусыйлаштыру Прогноз планын (программасын) расларга.
2. Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2020 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хосусыйлаштыру Прогноз планын (программасын) тормышка ашыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, регламент һәм җирлек Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы
Башлыгы урынбасары З. М. Әгълиева

**Ютазы район Советы**
**карарына Кушымта**
**№____ «____»____________ 20_____ ел**

## 2020 елга "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең муниципаль милекне ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫҢ ФАРАЗ ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)

### I бүлек. 2020 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыру бурычлары

2020 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (алга таба текст буенча – хосусыйлаштыруның прогноз планы) «Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 21.12.2001 ел, № 178-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез милекне алу үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»» 22.07.2008 ел, № 159-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2008 елның 30 маендагы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль милке белән эш итү тәртибе" турындагы № 115 Нигезләмәгә нигезләнеп эшләнде.

Муниципаль милек белән идарә итүнең базар икътисады шартларында формалаша торган система өлеше буларак, 2020 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыруның төп бурычлары «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль милек структурасын оптимальләштерү, шулай ук «дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 159-ФЗ номерлы федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" гы Федераль закон таләпләрен тормышка ашыру.

2020 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан район бюджетына салым булмаган керемнәр кертүне тәэмин итү;
- бюджетның керем өлешен арттыру;
- милекне карап тотуга район бюджетыннан чыгымнарны киметү.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге икътисадында хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә структур үзгәрешләр түбәндәге сәбәпләр аркасында көтелми:

- торак булмаган бинаны хосусыйлаштыру өчен тәкъдим ителгән объектта милекче алышынганда муниципаль берәмлектәге икътисади хәлгә сизелерлек йогынты ясый ала торган производство урнаштырылмый.;

Милекне сату хисабына район бюджетына якынча _ _ мең сум алу планлаштырыла.

Хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) нигезендә сатуга планлаштырылган объектның якынча бәясе базар бәясен үткәргәннән соң төгәлләштерелергә тиеш.

Хосусыйлаштырылырга тиешле объектның фаразланган бәясе базарның килеп туган конъюнктурасыннан чыгып исәпләнә.

2020 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган мөлкәт исемлеге муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

**II бүлек. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2020 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль милке**

| № т/б | объект | адрес | Хосусыйлаштыру ысулы | Фаразланган сату вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | №1000 санлы торак булмаган бина (билгеләнеше торак булмаган бина. тышкы стеналар материалы: кирпеч). мәйданы 285.6 кв. м. кадастр №16: 43: 100104:126 | Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу шәһ. , Икмәк тыкр.. 1 | ачык аукцион | 2 квартал | |